ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.04.2020 Олы Кайбыч ав. 196

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының мәгариф оешмаларына инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар тәэмин итү, шулай ук аларга кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 79 статьясы, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 декабрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Белем бирү объектларында инвалидларның файдалана алуы һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалану шартларын тәэмин итү, шулай ук аларга тиешле ярдәм күрсәтү тәртибен раслау турында» 2015 елның 9 ноябрендәге 1309 боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтада бирелгән «Татарстан Республикасы Инвалидлар җәмгыяте» Бөтенроссия оешмасының Татарстан Республика оешмасы белән килештереп, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының мәгариф оешмаларына инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар тәэмин итү, шулай ук аларга кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында һәм информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнашкан «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.А. Биккуловага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров

| | |
|---|---|
| Килештерелгән:<br>Инвалидлар җәмгыяте рәисе<br>_____________________ ФИАи | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 13. 04. 2020 ______<br>196 номерлы карары белән расланган |

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының мәгариф оешмаларына инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар тәэмин итү, шулай ук аларга кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибе

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының белем бирү оешмалары җитәкчеләре закон чыгару һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә инвалидларга мәгариф оешмаларына керүнең түбәндәге шартларын тудыра һәм тәэмин итә:

а) объектларга каршылыкларсыз керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

б) хезмәт күрсәтү урынына керү максатларында объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шул исәптән хезмәт күрсәтүче объект хезмәткәрләре ярдәмендә дә;

в) объектка керү урынында транспорт чарасыннан төшү һәм утыру мөмкинлеге, шул исәптән кресло-колясканы файдаланып һәм, кирәк булганда, объект хезмәткәрләре ярдәмендә;

г) хезмәткәрләре ярдәмендә күрү функцияләре бозылган инвалидларны озата бару һәм объект объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

д) объектка кергәндә һәм аннан чыкканда инвалидка ярдәм итү, инвалидка объект хезмәткәрләре ярдәмендә җәмәгать транспортының мөмкин булган маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларга хезмәт күрсәтү кагыйдәләре шул исәптән хезмәт алу өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү, хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында алар өчен аңлаешлы формада мәгълүмат алу өчен кирәкле ярдәм күрсәтү;

ж) мәгариф өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче органның һәм оешмаларның, күрү сәләте бозылган затлар (начар күрүчеләр) өчен рәсми сайтын җайлаштыру;

з) психологик-медицина-педагогик комиссиянең тиешле рекомендациясе яисә инвалидны реабилитацияләүнең индивидуаль программасы нигезендә белем бирү оешмасы тьюторы хезмәтләрен күрсәтүне тәэмин итү;

и) дәреслекләрне һәм уку ярдәмлекләрен, башка уку әдәбиятын, шулай ук коллектив һәм индивидуаль файдалануга өйрәтүнең махсус техник чараларын бушлай бирү;

к) мәгариф оешмалары хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга мәгариф өлкәсендә хезмәт күрсәтүләргә һәм объектларны башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңүдә кирәкле башка ярдәм күрсәтү.